КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 август г.Казань № 966

«ТатДорТрансИнвест» акционерлык
җәмгыяте төзү турында

«Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын реконструкцияләү. Болотников ур., Фрунзе ур., Горький шоссесы, Яшел ур., Музыкальная урамыннан алып федераль әһәмияткә ия «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок һәм «А-295 Йошкар-Ола - Зеленодольск автомобиль юлы «Идел» М-7 автомобиль юлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Казан шәһәре чигенә кадәр» юл объектларын төзеп бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының устав капиталында Татарстан Республикасының 100 процент катнашында «ТатДорТрансИнвест» акционерлык җәмгыятен төзү турындагы тәкъдим кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «ТатДорТрансИнвест» акционерлык җәмгыятен төзү буенча кирәкле оештыру чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы исеменнән төзелә торган акционерлык җәмгыятенең устав капиталына түләү буларак Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түбәндәге шартларда акча (алга таба – бюджет инвестицияләре) кертергә:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;

бюджет инвестицияләрен алучы - «ТатДорТрансИнвест» акционерлык җәмгыяте;

бюджет инвестицияләрен бирү максаты – төзегәндә «ТатДорТрансИнвест» акционерлык җәмгыятенең устав капиталына түләү;

бюджет инвестицияләрен бирү нәтиҗәсе – устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

бюджет инвестицияләре күләме - 10 мең сум.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин